**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«03» февраль 2022 ел — Биклән авылы — № 1

«Биклән авыл җирлеге Башкарма комитеты каршында балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссия турында» Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башлыгының 2021 елның 11 маендагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Балигъ булмаганнарның күзәтүсезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге уставы нигезендә, балигъ булмаганнар арасында күзәтүсезлекне кисәтү һәм хокук бозуларны профилактикалау, социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр белән профилактик эш алып бару максатыннан,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Биклән авыл җирлеге Башкарма комитеты каршында балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссия турында» Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башлыгының 2021 елның 11 маендагы 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Биклән авыл җирлеге Башкарма комитеты каршында балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссия составы» 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

Комиссия рәисе:
Биклән авыл җирлеге Башлыгы — М.Ш. Сәхбиев

Комиссия рәисе урынбасары:
«Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры — З.А. Гыймазиева

Комиссия секретаре:
Биклән авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары — А.Р. Бубенко

Комиссия әгъзалары:
Полиция участок инспекторы — Р.А. Гаязов

Укыту-тәрбия эшләре буенча мәктәп директоры урынбасары — В.С. Спиридонова

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Бикләән авыл җирлеге Башлыгы М.Ш. Сәхбиев